**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г. Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2024 елның 5 августы** **61-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында»Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020елның 05 июнендәге 32-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008елның25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023елның 08 декабрендәге 117-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2020 елның 05 июнендәге 32-РС номерлы карары белән расланган (2023 елның 05 маендагы 57-РС номерлы карар үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенә, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «кулланыла» сүзен «әгәр әлеге белешмәләрне бозуы җитди булмаса, кулланылырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7.1 пункт өстәргә:

«7.1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 2008елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1.1 статьясындагы 1 - 4.1-1 өлешләрендә билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм бурычларны бозган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар («Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон) федераль конституциячел законнарда, федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган җаваплылыкны тота, мондый тыюлар, чикләүләр һәм бурычлар аларга бәйле булмаган, әгәр федераль конституция законнарында, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләре нигезендә шундыйлар дип танылганнардан тыш.

Мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәү, шулай ук мондый бурычларны үтәү, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, зат тарафыннан үзенә бәйле булмаган, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүгә, шулай ук мондый бурычларны үтәүгә комачаулый торган хәлләр гамәлдән чыккан көннән алып бер айдан да соңга калмыйча тәэмин ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы урынбасары - Совет рәисе урынбасары

Т. П. Борһановага йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**